СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 18, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 18 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366) 94-2-37, факс (84366) 94-2-37. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Апаз авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 30 » сентябрь 2016 ел** **№ 46**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2017 елда Апаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Күмү урыннарын карап тоту | - торак пунктларда зиратларның мәгълүмати стендларын һәм схематик планнарын әзерләү һәм урнаштыру:<br>Апаз авылы – 1 штук;<br>Хәсәншәех авылы – 2 штук; | <br><br><br><br><br>1000<br>2000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Пөшәңгәр авылы – 1 штук;<br>Миржәм авылы – 1 штук;<br>Каратай авылы – 1 штук | 1000<br>1000<br>1000 |
| 2 | Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | - Хәсәншәех авылында суүткәргечне ремонтлау | 187500 |
| 3 | Территорияне төзекләндерүне оештыру (шул исәптән урамнарны яктырту) | -торак пунктларда яктырткычларны, лампаларны алыштыру:<br>Апаз авылы<br>Хәсәншәех авылы<br>Пөшәңгәр авылы<br>Миржәм авылы<br>Каратай авылы<br>Кзыл-Игенче авылы<br>- Пөшәңгәр авылында агачларны санитар кисү | <br><br><br>8500<br>9500<br>5900<br>3800<br>1600<br>700<br>3000 |
| 4 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге | -юлларга таш салу:<br><br>Апаз авылы (Тукай урамы 1 нче йорттан 17 йортка кадәр – 400м; Ленин урамы 1 нче йорттан 4 нче йортка кадәр – 150м; Бакча урамы 1 нче йорттан 6 нчы йортка кадәр – 200м; Гагарин урамы 1 нче йорттан 14 нче йортка кадәр – 400м);<br><br>Пөшәңгәр авылы (В.Әһлуллин урамы 1 нче йорттан 32 нче йортка кадәр – 400м; Нагорный урамы 10 нчы йорттан 12 нче йортка кадәр – 100м; 20 нче йорттан 32 нче йортка кадәр – 200м; Чапаев урамы 3 нче йорттан 9 нчы йортка кадәр – 100м); | <br><br>168750<br><br><br><br><br><br><br><br><br>112100 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Миржәм авылы (Мәскәү урамы 12 нче йорттан 19 нчы йортка кадәр – 100м; Н.Сафин урамы 1 нче йорттан 23 нче йортка кадәр – 200м, 25 нче йорттан 30 нчы йортка кадәр – 100м; Профсоюз урамы 3 нче йорттан 20 нче йортка кадәр – 150м);<br><br>Каратай авылы (Г.Камал урамы 1 нче йорттан 10 нчы йортка кадәр – 200м, 1 нче йорттан 19 нчы йортка кадәр – 150м; Һ.Такташ урамы 14 нче йорттан 19 нчы йортка кадәр – 200м);<br><br>Кзыл-Игенче урамы (Дальняя урамы 1 нче йорттан 14 нче йортка кадәр – 400м). | 73950<br><br>30650<br><br>15800 |
| | | | 627750 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Апаз авылы, Совет урамы 19 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы Хәсәншәех авылы, Космонавтлар урамы, 20 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, 42А йорты, Чапаев урамы 33 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Миржәм авылы, Н.Сафин урамы, 36 йорт.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ш. Садиков

СОВЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609003056